Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы
Урта Комар авыл җирлеге советы

КАРАР

2022 елның 10 ноябре № 24

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Урта Комар авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымы, гражданнарның үзара салымын җыю һәм куллану тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 56 статьясы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Урта Комар авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 81 статьясы нигезендә Урта Комар авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Урта Комар авыл җирлеге Советының 2014 елның 10 апрелендәге 17 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Урта Комар авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымы, гражданнарның үзара салымын җыю һәм куллану тәртибе турында нигезләмәгә (Урта Комар авыл җирлеге Советының 2016 елның 01 октябрендәге 2 номерлы, 2018 елның 17 сентябрендәге 24 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5.1.А пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1.А. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләүдән түбәндәге категория затлар азат ителә:

- 1 төркем инвалидлары;
- көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлар (курсантлар);
-18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналар;
- 80 яшькә җиткәннәр һәм аннан өлкәнрәкләр;
- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә срокры хәрби хезмәткә чакырылган затлар;
- Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзалары;
- локаль сугышларда һәм Украинада махсус операция барышында һәлак булганнарның гаиләләре.

2. Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып халыкка җиткерергә, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Урта Комар авыл җирлеге башлыгы: Ю.И. Исынбаев